КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 июнь г.Казань № 490

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь,1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2017 ел, 7 август, 562 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибендә:

2 пунктта:

утыз дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – ТР ЯЭМ);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциячел булмаган оешма (алга таба – Төбәк операторы).»;

6 пункт таблицасында:

29 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «29. | ТР ХЭБТИhСЯМ | Татарстан Республикасында җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләр арасыннан балага айлык пособие билгеләнгән 4-17 яшьлек балалар турында мәгълүмат | электрон | хисап аеның 20 сенә кадәр | ТР ССМ, ТР ЯШМ, ММИ»; |

түбәндәге эчтәлекле 30 пунктча өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «30. | Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә махсус счет хуҗасы булган төбәк операторы, ИК | Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлауга айлык кертемнәр түләү буенча бурычлар турында мәгълүмат | электрон, документлар | сорату буенча | МПРУ бүлекләре». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин